**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.09.2013 № 5-19/тэ

Казан ш.

***«ТГК Уруссинская ГРЭС» ЯАЖ тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында***

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар буенча хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ТГК Уруссинская ГРЭС» ЯАЖ тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә әлеге карар кушымтасына туры китереп тарифлар билгеләргә

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 26 декабрь, 2011 ел, № 5-55/э карарының 1 һәм 2 кушымталарының 2 пункты 2013 елның 1 октябреннән үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.09.2013 № 5-19/тэ
карарына кушымта

## «ТГК Уруссинская ГРЭС» ЯАЖ тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар

(НДС исәпкә алмыйча)

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|
| | | | су | пар |
| Җылылык энергиясен тапшыру матдәсе җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагына (чыганакларына) хуҗа булган җылылык белән тәэмин итүче оешмадан бирелгән җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә тариф | | | | |
| 1 | «ТГК Уруссинская ГРЭС» ЯАЖ | Бер ставкалы, сум/куб.м | 30,38 | 89,75 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге